**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«24» 09 2021 ел Яр Чаллы № 2872

Гражданнарның урманнарда булуын
һәм аларга транспорт чаралары белән
керүен чикләүне кертү турында

1. Тукай муниципаль районы территориясендә урманчылыклар чикләрендәге урман фонды территориясендә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне һәм урманнарда эшләрнең билгеле бер төрләрен башкаруны бу карар үз көченә кергән көннән 21 календарь көнгә (гамәлдәге законнар нигезендә урманнардан файдалану буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларның гомуми файдаланудагы юллар буйлап үтәли йөрүдән тыш) кертергә.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, аеруча саклана торган табигать территорияләре житәкчеләренә, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, шәхси эшмәкәрләргә, вазыйфаи затларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.02.20021 ел, № 321-р күрсәтмәсе нигезендә янгынга каршы кисәтү, профилактика чаралары комплексын үткәрүне тәэмин итәргә.

3. "Алабуга урманчылыгы»ДКУнең Татарстан участок урманчылыгына:

-Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан янгынга каршы профилактика чараларын үтәүгә дәүләт йөкләмәсе нигезендә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү эшен оештырырга;

-Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 1нче мартында 101 номерлы боерыгы белән расланган “2021 елның янгын чыгу куркынычы сезоны чорына Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерү буенча жыелма план нигезендә” урман янгыннарын сүндерүгә бәйле һәлакәттән коткару эшләрен үткәрүне гамәлгә ашырырга;

-тиешле чикләүне кертү турында һәм аның гамәлдә булу чоры турында кисәтү аншлагларын урнаштыруны оештырырга;

- урман юлларына шлагбаумнар куюны оештырырга;

-ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә тәүлек буе кизү торуны оештырырга һәм урман массивларында патруль торуны көчәйтергә;

-ял һәм бәйрәм көннәрендә урманнарның кешеләр күпләп ял итү урыннарында вакытлыча постлар оештырырга;

-халыкка төбәк телеканалларында, радиотапшыру станцияләрендә, вакытлы басма матбугатларда табигый янгыннар торышы һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык турында өстәмә мәгълүмат бирүне оештырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин